ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2019 г. Заинск № 548

**«Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамәләр һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен раслау хакында Административ регламентны раслау турында»**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210нчы (27.07.2010) Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 360нчы карары (06.03.2018), Зәй муниципаль районы Уставының 45нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамәләр һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен раслау хакында Административ регламентны кушымта нигезендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы башкарма комитетының оештыру бүлеге әлеге карарны муниципаль районның http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Район башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Р.Р. Исламова
3 47 87